| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
| **РЕШЕНИЕ** | с.Старое Дрожжаное | **КАРАР** |

2023 елның 9 ноябре № 32/5

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт турында» 2020 елның 30 гыйнварындагы 42/4 номерлы Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2020 елның 30 гыйнварындагы 42/4 номерлы карары белән расланган Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (03.06.2020 № 45/4, 12.11.2020 № 3/6, 05.02.2021 № 6/4, 16.08.2021 № 11/3, 13.02.2023 № 25/1, 20.06.2023 № 29/6, 17.08.2023 № 30/3 номерлы Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**1) 9 статьяда:**

**5 пунктта** «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

**7 пунктта** «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

**2) 11 статьяга** түбәндәге эчтәлекле **1.1 пункт өстәргә:**

«1.1. Муниципаль хезмәткәргә әлеге статьяның 8 пунктында күрсәтелгән белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»;

**3) 19 статьяга** түбәндәге эчтәлекле **1.1 пункт өстәргә:**

«1.1. Муниципаль хезмәткәр «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка

федераль законнарда коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне, чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән өчен һәм «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә коррупциягә каршы тору максатларында башка федераль законнар белән дә, мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү аңа бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе дип танылса, җаваплылыктан азат ителә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров